КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 август г.Казань № 598

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 1 ноябрь, 998 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы ведомство буйсынуындагы кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 1 ноябрь, 998 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 6 июль, 553 нче, 2020 ел, 30 декабрь, 1237 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 20 июнь, 587 нче, 2022 ел, 26 август, 910 нчы, 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче, 2023 ел, 16 октябрь, 1312 нче, 2024 ел, 10 июнь, 416 нчы, 2024 ел, 26 сентябрь, 832 нче, 2025 ел, 18 апрель, 244 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы ведомство буйсынуындагы кайбер оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 7.8.1 пунктча өстәргә:

«7.8.1. Хезмәтнең интенсивлыгы өчен стимуллаштыручы характердагы түләүләр ($B_{it}$) «Республика физик культура һәм яшүсмерләр спорты үзәге» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе җитәкчесенә, аның урынбасарларына билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times \frac{D_{it}}{100\%},$$

монда:

$O_d$ - «Республика физик культура һәм яшүсмерләр спорты үзәге» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе җитәкчесенең, аның урынбасарларының вазыйфаи оклады;

$D_{it}$ – хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләү күләме.

Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләмнәре әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада китерелде.»;

әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы буйсынуындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 14 август, 598 нче
карары редакциясендә)

Аерым мәгариф һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләмнәре

| Оешма исеме | Һөнәри квалификация төркеменең, вазыйфасының исеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| «Физик культура һәм яшүсмерләр спорты буенча республика үзәге» дәүләт бюджет белем бирү учреждениесе | оешма җитәкчесе, оешма җитәкчесе урынбасарлары | 50,0 |

________________________